ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УСАД
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422710, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Усад авылы, Совет ур., 41

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
УСАДСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

422710,Республика Татарстан,Высокогорский район,
с.Усады, ул. Советская, 41

тел./факс 8(84365) 73-2-75, e-mail: Usad.Vsg@tatar.ru

---

КАРАР — ПОСТАНОВЛЕНИЕ

19 август 2019 ел — № 13

## Биектау муниципаль районы Усад авыл җирлеге милке турында мәгълүматны ачу турында Тәртипне раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасында милек турында мәгълүматны ачу турында Нигезләмәне раслау турында”, 2008 елның 16 маендагы 327 номерлы Карары нигезендә, Татарстан Республикасы территориясендә инвестицион активлыкны арттыру, шулай ук муниципаль милекне тагын да нәтиҗәлерәк һәм рациональ куллану максатыннан, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Усад авыл җирлеге Башкарма комитеты, КАРАР БИРӘ:

1. Теркәлгән Биектау муниципаль районы Усад авыл җирлеге милке турында мәгълүматны ачу турында Тәртипне расларга.
2. Әлеге карарны Биектау муниципаль районы рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникацияләр челтәрендә http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адресы буенча һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында” Интернет мәгълүмат-телекоммуникацияләр челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).
3. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Усад авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе — Р.А.Биктагирова

Кушымта
«Расланган»
Татарстан Республикасы
Биектау муниципаль районы
Усад авыл җирлеге
Башкарма комитеты карары белән
190.08.2019 № 13

**Биектау муниципаль районы**
**Усад авыл җирлеге милке турында мәгълүматны ачу турында**
**Тәртип**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Усад авыл җирлеге милке турындагы мәгълүматны ачу турындагы Тәртип “Мәгълүмат, мәгълүмати технологияләр һәм мәгълүматны яклау турында", 2006 елның 27 июлендәге 149-ФЗ , "Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында", 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон, "Муниципаль сер турында", 1993 елның 21 нче июлендәге 5485-1 номерлы Федераль закон, “Татарстан Республикасы дәүләт милке турында”, 2005 елның 8 апрелендәге 65-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, “Татарстан Ресубликасы милкен хосусыйлаштыру турында”, 2004 елның 26 июлендәге 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасы Җир һәм милек мөнәсәбәтләре министрлыгы мәсьәләләре”, 2007 елның 22 августындагы 407 номерлы Карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 елның 25 сентябрендәге 1426-р номерлы карарлары нигезендә эшләнгән һәм Биектау муниципаль районы Усад авыл җирлеге Башкарма комитеты карары белән ачыла торган Биектау муниципаль районы Усад авыл җирлегенең муниципаль милке турындагы мәгълүмат составын, шулай ук аны ачу тәртибен һәм вакытын билгели.

1.2. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Усад авыл җирлегенең муниципаль милке турындагы мәгълүматны ачу дигәндә аның белән кызыксынучы барлык кешеләрнең дә аннан файдалана алуын тәэмин итү аңлашыла.

1.3. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Усад авыл җирлегенең муниципаль милекне исәпкә алу объектлары турында мәгълүмат Биектау муниципаль районы Усад авыл җирлеге Башкарма комитеты тарафыннан Россия Федерациясе, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актлары, муниципаль норматив хокукый актлар нигезендә бирелә. Мәгълүмат бирүдән баш тарту соратып алына торган белешмәдә дәүләт серен тәшкил итүче мәгълүмат булган очракта гына мөмкин.

1.4. Юридик затларның мәнфәгатьләренә зыян китереп мәгълүмат куллану Россия Федерациясенең гамәлдәге законнарында каралган җаваплылыкка китерә.

1.5. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Усад авыл җирлеге муниципаль милке турындагы мәгълүмат Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Усад авыл җирлеге муниципаль милке Реестрында теркәлгән белешмәләр, шулай ук Биектау муниципаль районы Усад авыл җирлеге милкендә булган Биектау муниципаль районы Усад авыл җирлеге Башкарма комитетының мәгълүматлар базасында булган җир кишәрлекләре турындагы белешмәләр күләмендә бирелә.

1.6. Биектау муниципаль раойны Усад авыл җирлеге муниципаль милке турындагы мәгълүматны ачу мәгълүмат тарату һәм кызыксынган затларга мәгълүмат бирү рәвешендә гамәлгә ашырыла.

Мәгълүмат тарату массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгару һәм

сайтта "Интернет" челтәрендә урнаштыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

Мәгълүмат бирү кызыксынган затларның язма мөрәҗәгатьләре буенча, шул исәптән аерым милек объектлары буенча да гамәлгә ашырыла.

**2. Мәгълүмат тарату**

2 .1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Усад авыл җирлегенең "Интернет" челтәрендә аны урнаштыру юлы белән таратыла торган муниципаль милек турында мәгълүматы түбәндәге мәгълүматлар исемлеге белән билгеләнә (мондый мәгълүматлар закон белән чикләнгән мәгълүматны үз эченә алган очраклардан тыш):

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Усад авыл җирлеге муниципаль учреждениеләре исемлеге (исеме, урнашу урыны);

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Усад авыл җирлеге муниципаль унитар предприятиеләре исемлеге (исеме, урнашу урыны);

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Усад авыл җирлеге милкендә булган устав капиталы өлеше (акцияләр пакетлары) хуҗалык җәмгыятьләре исемлеге (хуҗалык җәмгыятенең исеме, урыны, муниципалитетның устав капиталында өлеше);

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Усад авыл җирлеге милкендә булган күчемсез мөлкәт (биналар, бүлмәләр) исемлеге (исеме, урнашу урыны, мәйданы, максатчан билгеләнеше, куллануны чикләү, өченче затларның хокукларын йөкләү);

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Усад авыл җирлеге муниципаль милкен хосусыйлаштыруның фараз планы (программасы);

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Усад авыл җирлеге муниципаль милкен хосусыйлаштыруның фараз планы (программасы) үтәлеше турында хисап.

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Усад авыл җирлегенең муниципаль милке турында күрсәтелгән мәгълүмат шулай ук массакүләм мәгълүмат чараларында басылып чыгарга мөмкин.

2.2. Әлеге нигезләмәнең 2.1. пунктында күрсәтелгән 1 гыйнварга булган белешмәләр, финанс елы тәмамланганнан соң дүрт айдан да соңга калмыйча, Биектау муниципаль районының рәсми сайтында ел саен басылып чыгарга тиеш.

2.3. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Усад авыл җирлеге муниципаль милкендә булган мөлкәт объектлары турында мәгълүматны ачу, хосусыйлаштыру турындагы законнар белән билгеләнгән күләмдә гамәлгә ашырыла.

**3. Кызыксынган затларга мәгълүмат бирү**

3.1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Усад авыл җирлеге муниципаль милек реестрында теркәлгән аерым милек объектлары буенча мәгълүмат (алга таба – исәп объекты) теләсә кайсы кызыксынган затларга мөрәҗәгать итү буенча Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Усад авыл җирлеге муниципаль милек реестрыннан хат формасында яки өземтә рәвешендә бирелә.

3.2. Исәпкә алу объектлары турында мәгълүмат (яки аны бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән карар) Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Усад авыл җирлеге Башкарма комитеты тарафыннан мөрәҗәгатьне теркәгән көннән алып 30 көннән дә артмаган срокта бирелә.

3.3. Биектау муниципаль районы Усад авыл җирлеге муниципаль милек реестрыннан өземтә түбәндәге очракларда бирелә:

исәп объектлары милек ияләренә яки аларның законылы вәкилләренә;

исәп объектлары милек ияләреннән яки аларның законылы вәкилләреннән

ышанычнамә алган физик һәм юридик затларга;

Татарстан Республикасы хисап палатасына;

җирле үзидарә органнарына һәм Татарстан Республикасы, Россия Федерациясенең башка субъектлары дәүләт хакимияте органнарына;

дәүләт хакимияте федераль органнарына, шул исәптән:

күчемсез милеккә хокукларны дәүләт теркәвен һәм алар белән алыш-бирешне тормышка ашыручы органнарга;

салым органнарына;

судларга, хокук саклау органнарына, исәп объекты һәм (яки) аларны милек ияләре белән бәяле эшләр булган суд приставларына-башкаручыларга;

федераль монополиягә каршы органга һәм аның Татарстан Республикасындагы территориаль органына.

3.4. Әлеге Тәртипнең 3.3. пунктында күрсәтелмәгән кызыксынган затларга Биектау муниципаль районы Усад авыл җирлеге муниципаль милке Реестрында булган хисап объектларының урнашкан урыны турында мәгълүмат кына бирелә.

3.5. Соратып алына торган мәгълүматны язмача бирүдән баш тарту дәлилләнгән булырга тиеш.

Соратып алына торган мәгълүматны бирүдән баш тарту өчен нигез булып түбәндәге сәбәпләр тора:

мөрәҗәгатьтә законнар белән чикләнгән мәгълүматны үз эченә алган белешмәләр соратылган очракта;

мөрәҗәгатьнең эчтәлеге әлеге затны кызыксындырган мәгълүмат объектны берсүзсез билгеләргә мөмкинлек бирмәгән очракта;

мөрәҗәгатьтә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Усад авыл җирлеге муниципаль милек реестрында мәгълүматлар булмаган мөлкәт объекты күрсәтелгән очракта.